| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2020 ел Баулы шәһәре №213

«2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасы буенча гражданнарны исәпкә куйганда һәм аларга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясы нигезендә, Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 5 маендагы 112 номерлы карар белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую максатларында, гражданның торак белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгели торган торак мәйданының исәпкә алу нормасын гаиләнең бер әгъзасына 18 квадрат метр күләмендә расларга.

2. «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасы буенча гаилә әгъзасына торак бирү нормасын торакның гомуми мәйданының 18 квадрат метры күләмендә расларга, әмма ике кешелек гаилә өчен гомуми торак урынының 42 квадрат метрыннан да ким итеп түгел.

Җитәкче И.И. Гозәеров